ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 442-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.Н. Шәфигуллин, Р.Р. Гайзатуллин, М.Һ. Галиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 442-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектына төзәтмәләр 2023 елның 13 августына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты 2023 елның 13 сентябренә кадәр, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, әлеге закон проектын эшләп бетерергә һәм аны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 13 июле
№ 2053-VI ДС

Проект Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Л.Н. Шәфигуллин,
Р.Р. Гайзатуллин, М.Һ. Галиев
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына**
**үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» 2022 елның 23 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) законнарда билгеләнгән очракларда хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү, билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү;»;

2) 5 статьяда:

а) исемендә «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешнең 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) законнарда билгеләнгән очракларда хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү, билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү;»;

в) 2 өлешнең беренче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр турында» 2023 елның 20 июнендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – Татарстан Республикасы Законы) кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнде.

Татарстан Республикасы Законы белән «Хуҗалык җәмгыятьләренең һәм ширкәтләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт вәкилләренең катнашу тәртибе турында» 2000 елның 19 октябрендәге 383 номерлы Татарстан Республикасы Законы үз көчен югалткан дип танылды һәм хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү, билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне актуаль җайга салу билгеләнде.

1. Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешендә дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү, билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү түбәндәге хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына гамәлгә ашырыла дип карала:

1) аларга карата махсус хокукны («алтын акция») куллану турындагы карар кабул ителгән;

2) акцияләре (устав капиталларындагы өлешләре) Татарстан Республикасы милкендә булган;

3) акцияләренә (устав капиталларындагы өлешләренә) хуҗалык җәмгыятьләре ия булган, аларның акцияләренең (устав капиталларындагы өлешләренең) 50 проценттан артыгы Татарстан Республикасы милкендә була.

Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 7 статьяларында тиешенчә Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү, билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү мәсьәләләре җайга салына.

Шуңа бәйле рәвештә закон проекты белән «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» 2022 елның 23 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына әлеге затларның вәкаләтләрен төгәлләштерүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнарны таләп итмәячәк.